*Кушымта*

**Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының 2026 елның 1 гыйнварыннан 30 июненә кадәрге чорда гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүләре турында**
**СТАТИСТИК МӘГЪЛҮМАТЛАР**

| Министрлык/ Ведомство | Гражданнардан 2026 елның 1 яртыеллыгында кергән барлык мөрәҗәгатьләр * | Гражданнардан 2025 елның 1 яртыеллыгында кергән мөрәҗәгатьләр | Язма булмаган мөрәҗәгатьләр (шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша) | Шул исәптән җитәкчеләр тарафыннан шәхсән кабул итү | Шул исәптән видеоконференцияләр системасы буенча кабул итү | Язма мөрәҗәгатьләр | Шул исәптән Интернет-кабул итү бүлмәсе аша кергән** | Кире элемтә платформасы аша кергән*** | Контрольгә алынган | Урынга чыгып тикшерелгән | Уңай хәл ителгән |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы | 1585 | 1859 | 17 | 7 | - | 1568 | 268 | 3 | 1585 | - | 16 |

***Барлык мөрәҗәгатьләр = язма һәм язма булмаган мөрәҗәгатьләр бүлемнәренең** уртак суммасы.
****Интернет кабул итү бүлмәсе** язма мөрәҗәгатьләр санына керә.
***Кире элемтә платформасы аша кергән мөрәҗәгатьләр **язма мөрәҗәгатьләргә керми.**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 2026 елның 1 яртыеллыгында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә
АНАЛИЗ

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 2026 елның 1 яртыеллыгында гражданнардан **1585** мөрәҗәгать кергән. Бу 2025 елның шушы чоры белән чагыштырганда 274 мөрәҗәгатькә (14,7%) кимрәк (ул чорда 1859 мөрәҗәгать булган).

Мөрәҗәгатьләрнең күбесе - **1568** берәмлек - язма рәвештә, Интернет-кабул итү бүлмәсе аша - **268** берәмлек кергән. Кире элемтә платформасы (КЭП) аша **3** мөрәҗәгать алынган.

Татар телендә мөрәҗәгатьләр кермәде.

**418** мөрәҗәгать буенча җаваплар җибәрелгән, шул исәптән **16** мөрәҗәгать буенча уңай карарлар кабул ителгән, **402** мөрәҗәгать буенча аңлатмалар бирелгән. **1057** мөрәҗәгать компетентлы органнарга җибәрелгән. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлегенә бәйле **74** мөрәҗәгать буенча тиешле чаралар күрелде. Җәмәгать судьялары аппаратлары эшенә карата **5** шикаять мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан кире алынды. Мәгълүмати характердагы **8** документ игътибарга алынды. Хәзерге вакытта **23** мөрәҗәгать буенча эш алып барыла.

2026 елның беренче яртыеллыгында Министрлык җитәкчелеге тарафыннан **17** кеше шәхсән кабул ителде.

Төп тематик категорияләр буенча кергән мөрәҗәгатьләр саны түбәндәгечә бирелә:

| **Тематика** | **2026 ел** | **2025 ел** | **Динамика** |
|---|---|---|---|
| Дәүләт, җәмгыять, сәясәт | 229 | 198 | +31 (15,7%) |
| Торак-коммуналь өлкә | 32 | 58 | −26 (44,8%) |
| Оборона, куркынычсызлык, законлылык | 1101 | 1408 | −307 (21,8%) |
| Социаль өлкә | 159 | 119 | +40 (33,6%) |
| Икътисад | 103 | 142 | −39 (27,5%) |

Мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны кимүенең төп сәбәбе - федераль һәм җәмәгать судьялары һәм аларның аппаратлары эшчәнлегенә бәйле шикаятьләрнең кимүе. 2026 елның 1 гыйнварыннан 1 июленә кадәр 1047 мөрәҗәгать кергән, бу 2025 елның шул ук чорында кергән 1271 мөрәҗәгатькә караганда 17,6% ка кимрәк.

Шикаятьләр күләменең кимүе Министрлык тарафыннан коллекторлык агентлыклары вәкилләре һәм җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләре белән эшлекле очрашу уздыру нәтиҗәсе булып тора. Очрашуда якларга эшчәнлекнең аерым проблемалы аспектлары буенча киңәйтелгән аңлатмалар бирелде. Җайга салынган эшчәнлек һәм позицияләрне төгәлләштерү нәтиҗәсендә аңлашылмаучылыкларның күбесе суд участогында ук хәл ителә, бу исә Министрлыкка шикаять җибәрү зарурлыгын юкка чыгара.

“Дәүләт, җәмгыять, сәясәт” категориясе буенча мөрәҗәгатьләр күләме гражданнарның муниципаль норматив хокукый актлар буенча актив фикер алышуына бәйле рәвештә артты.

“Социаль өлкә” тематикасы буенча мөрәҗәгатьләр саны гражданнарның дәүләт органнары эшчәнлеге практикасына кертү өчен фәнни эшләнмәләр тәкъдим итү мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә артты.

2025 елның беренче яртыеллыгында гражданнардан хуҗасыз хайваннарны эвтаназияләү турындагы закон кабул ителүгә каршы 32 мөрәҗәгать кергән. 2026 елның шул ук чорында мондый мөрәҗәгатьләр теркәлмәде, моңа бәйле рәвештә “Икътисад” тематикасы буенча мөрәҗәгатьләр саны кимеде.

Махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары **21** тапкыр мөрәҗәгать иткән.

Гражданнар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Казан шәһәре, Кремль урамы, 16 йорт.

Министр, министр урынбасарлары һәм эшләр белән идарә итүче гражданнарны расланган график нигезендә кабул итәләр:

| | |
|---|---|
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы, министр | сишәмбе, 14:00 дән 18:00 гә кадәр |
| Гомзик Илья Александрович министрның беренче урынбасары | пәнҗешәмбе, 14:00 дән 18:00 гә кадәр |
| Ибәтов Мөхәррәм Мансур улы, министр урынбасары | җомга, 14:00 дән 18:00 гә кадәр |
| Низамиев Марат Фәрит улы, министр урынбасары | чәршәмбе 14:00 дән 18:00 гә кадәр |
| Боровков Максим Сергеевич министр урынбасары | дүшәмбе, 14:00 дән 18:00 гә кадәр |

Гражданнардан Министрлыкка кергән барлык мөрәҗәгатьләр дә, куелган мәсьәләләрнең тематикасын һәм Министрлык компетенциясен исәпкә алып, “Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә каралалар. Барлык мөрәҗәгатьләргә дә җаваплар законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән.